

Рамазан ае – моселман календарендә ин изге һәм ин кадерле ай.
Ул моселманнар очен ураза тоту, физик һәм рухи яктан чистарыну ае. Ләйләт әл-кадр кичәсе булганга һәм бу айда Коръән аятьләре инә башлаган очен кадерле. Мордовиядә яшәvче моселманнар, барлык халык белән бергә, быел 12 апрельдә Рамазан аена аяк басты. Беренче тәравих намазы 20 рәкәгать итеп 12 апрель конне ястv намазыннан сон укылды. Ураза быел 30 кон тотыла. Гает намазы 13 майда укылачак.       Ни кызганыч, былтыр тәравих намазларын жәмәгатьчелек белән бергә укый алмаган идек. Быел Мордовия мәчетләребез ачык, әмма бу биналарда барлык санитар-эпидемиологик таләпләрне vтәргә тиеш булабыз. Тагы мәчетләребездә социаль дистанция сак-ларга тиешбез. Анда, сулыш органнарын саклау очен, битлекләр кулланырга кирәк, дип кисәтә дин әхелләребез.
Рамазан аенда фитырны ничек бирергә – азык-толек беләнме яки акчалатамы дигән сораулар халык арасында, бигрәк яшьләр арасында туа. Хәнәфи мәзһәбе буенча, фитыр сәдакасын (бары тик мохтаж моселманнарга гына бирелә), ризык, азык-толек белән генә тvгел, акчалата да бирергә момкин. Мохтажлар бу акчаны vзләре теләгәнчә (бурыч, дәвалану һәм коммуналь хезмәтләр очен тvләv, дарулар, кием-салым, азык-толек сатып алу һ.б. очен) тота ала.
Тагы Рамазан – изге гамәлләр ае. Әйдәгез бер-беребезгә мәрхәмәтле булыйк, изге гамәлләр эшләп һәр конебез vтсен. Бу айда башка вакытны эшли алмый калган игелекләрне башкарырга тырышыйк.